ГЛАВА СОБОЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.7, с. Шеланга, 422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Совет ур., 7 нче йорт, Шеланга авылы, 422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

23.10.2023 | № 1

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1

с. Соболевское

«Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 15 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга :

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авылы җирлеге Карамышиха авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтүгә ризалыгыгыз бармы:

- Карамышиха авылындагы зират территориясен төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Карамыш авылы, Үзәк урамы адресы буенча 5А йорт яны территориясендә 10:00 сәгатьтә уздырырга.

4. Соболевский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова